Минзәлә гимназиясе укучылары газетасы

# ЯШЬЛЕК

Сентябрь 2025

## Бу санда:

**2-3 бит – Җәй белән хушлашу**

**4 бит – “Яңа шәхес” рубрикасы**

**5 бит – “Нәниләр сөйли” рубрикасы**

**6-7 бит – гимназия яңалыклары**

**8 бит – Куңелле тәнәфес**



***Белем бәйрәме белән!***

1 сентябрь көнне гимназиядә белем көненә багышланган тантаналы линейка узды. Бу уку елында 1нче сыйныфка 21 бала килде. Барысы гимназиядә 324 укучы белем ала. Барыгызны да белем бәйрәме белән котлыйбыз!



***Өлкәннәр көне***




Хөрмәтле хезмәт ветераннары! Заман авырлыкларына бирешмичә илебез уңышы өчен көчегезне кызганмагансыз. Бу дөньяда куйган хезмәтләрегез, кылган изгелекләрегез өчен рәхмәт сезгә! Без, яшьләр, сезнең киңәшләрегездән тайпылмабыз, үрнәк булырга тырышырбыз! Саулык-сәламәтлектә, дөньяга ямь биреп яшәгез, урыннарыгыз өйнең түрендә булсын! Бәйрәмегез белән!

***Хәйрия ярминкәсе узды***

Гимназиябездә татар милли ризыкларын сатуга юнәлдерелгән ярминкә узды. Бу көнне җыелган барлык сумма илебез данын яклап сугышта катнашучыларга медикаментлар алуга тотылачак һәм "Ялкын" үзәгенә тапшырылачак.



# Саубул, Җәй!





**1. Җәйге яллар нәрсәсе белән истә калган?**

**Галиев Аяз:** “Мин быел тугызынчы сыйныфны тәмамладым. Җәйнең беренче көннәреннән үк консультацияләргә йөрдем, тырышып имтиханнарга әзерләндем. Шунысы куанычлы: имтиханнарның барысын да яхшы билгеләренә тапшырдым.

**Гарипов Салават**: “Быелгы җәйге яллар минем өчен бик истә калды. Чөнки мин тугызынчы сыйныфны тәмамладым. Сыйныф белән имтиханнарга, чыгарылыш кичәсенә әзерләндек.

**Гильфанова Алина**: “Мин июль аенда гаиләм белән Соль - Илецкийга ял итәргә бардым. Бу шәһәр үзенең тозлы күлләре, табигате белән истә калды.

**Буранов Рөстәм**: “Мин машина йөртү мәктәбендә укыдым. Имтихан бирәсе көнне бик борчылдым. Тырышып әзерләнүләрем юкка булмады: компьютердагы имтихан сорауларын хатасыз эшләдем. Машина йөртү буенча да имтиханны уңышлы тапшырдым. Тиздән кулымда машина йөртү таныклыгы булачак.

**Хәсәнов Инсаф:** “Быелгы җәй минем өчен авыррак булды. Сәламәтлегем какшау сәбәпле, эшкә урнаша алмадым. Сәламәтлегемне ныгытырга, дәваланырга туры килде.

**Хәбирова Ралина:** “Тугызынчы сыйныфны тәмамлау, кулыма аттестат алу - минем өчен иң истәлекле вакыйга. Чыгарылыш кичәсенә әзерләнү, матур киемнәр алу, таңны каршы алу - барысы да искитмәле булды.

**Зарипова Самира:** “Мин бик тырышып имтиханнарга әзерләндем. Имтиханнарны уңышлы тапшыргач, чыгарылыш кичәсенә әзерлек башланды.

**Галиева Камилә:**“Минемчә, җәй – ул иң яраткан һәм көтеп алынган вакыт. Әти-әниләр отпуска ала, без мәктәп тормышыннан ял итәбез”.

**Фаттахова Зарина:** “Мин имтиханнарга әзерләндем. Шулай да Чаллыга, Түбән Камага барып, гаиләбез белән ял итәргә дә җитештек”.

**Закиров Илдан:** “Имтиханнарга әзерләндем, аттестат алдым. Җәйге ял вакытында яна танышлар таптым”.

**2. Җәйге ялларда мин нишләдем?**

**Галиев Аяз:** “Мин бер ай “Камский бекон” оешмасында эшләдем. Яңадан ял итәргә авылга, әби-бабаем янына кайттым. Аларга йорт эшләрендә булыштым. Абыем белән балыкка да йөрдек.

**Гарипов Салават:** “Казанга ел саен барабыз. Быел да Казанда булдым. Бауман урамнарында йөрдем, Сөембикә манарасында, Кол Шәриф мәчетендә булдым. Өйдә әтигә булыштым. Авылга кайтырга да җитештем”.

**Гильфанова Алина:**“Җәйге ялда имтиханнар турында да онытмадым. Көн ахырында вебинарлар карадым, мисаллар чиштем, сочинениеләр яздым. Дусларым белән дә очраштым. Бергә футбол уйнадык, саф һавада йөрдек”.

**Буранов Рөстәм:** “Җәй уртасында апам белән Алабуга шәһәрендә булдым. Андагы тарихи урыннар белән таныштым, педагогия институтында булдым. Борынгы, тарихи шәһәр булса да, матур урыннар күп икән”.

**Хәсәнов Инсаф:** “Китаплар укыдым, шахмат белән шөгыльләндем. Авылга кайттым, анда яңа дуслар таптым”.

**Хәбирова Ралина:** “Җәй – ул итә торган вакыт. Рәхәтләнеп ял иттем, яңа дуслар таптым. Ләкин җәй бик тиз үтеп китте шул”.

**Зарипова Самира:** “Бакча һәм йорт эшләрендә әнигә булыштым. Әле эшкә дә урнаштым, официант булып эшләп карадым. Җәй сизелмичә үтеп китте”.

**Галиева Камилә:** “Мин җәйне авылда үткәрдем. Мөгаен, авылдагы җәй таңнар атуы, чәчәкләрнең хуш исләре, кошлар сайравы белән күңелледер. Шулай да мәктәпне һәм сыйныфташларымны сагынырга да өлгердем”.

**Фаттахова Зарина:** “Без быел җәй көне песи баласы алдык. Минем күпчелек вакытым шул песи баласы белән үтте инде. Быелгы җәй миңа ошады”.

**Закиров Илдан:** “Без авылга кайттык. Йорт эшләрендә булыштым. Дусларым белән балыкка, су керергә йөрдек. Җәй ахырында китап укыдым һәм мәктәпкә әзерләндем”.



# “Яңа шәхес”



**Кыскача мәгълүмат:**
**Исеме: Газизуллина Әлфия Хасан кызы**
**Туган көне:9 июнь**
**Шөгыльләре: бәйләргә, чәчәкләр үстерергә бик яратам. Ротангтан кашполар үрү белән шөгыльләнәм.**
**Яраткан ризыклары: голубцы**
**Яраткан фильмы: “Обнимая небо”**

- **Сез нинди уку йортын тәмамладыгыз?**
Алабуга дәүләт педагогия институтында белем алдым.
- **Өченче мәктәптә бик озак еллар математика укыткансыз. Ул мәктәптән китәргә кыен булмадымы? Гимназиягә килергә ничек тәвәкәлләдегез?**
- Коллегаларым белән 30 ел бик дус, тату эшләдек. Бер-беребезнең гаиләләребезне бик яхшы беләбез. Балаларыбызны гына түгел, оныкларыбызны да яхшы беләбез. Шуңадыр инде, алар белән аерылышу күңелемә бик авыр булды.
Бик күп еллар элек, без, Минзәлә районыннан 10 укытучы, аттестация үттек. Биш ел буе, Татарстан мәктәпләренә департамент тикшерү белән йөрдек. Безгә авыл мәктәпләренә дә еш барырга туры килде. Миңа авыл мәктәпләре бик ошады. Анда килеп керү белән атмосфера да, мөхите дә икенче төрле икәне сизелеп тора. Авыл мәктәпләрендә, шәһәр мәктәпләре белән чагыштырганда, тынычлык хөкем итә. Анда укучы балалар да азрак иде. Аларның коллективлары бик дус, барлык эшләрне дә бергә башкаралар. Минем дә шундый тыныч авыл мәктәбендә эшлисем килде. Ә шәһәрдә, гимназиядән башка, андый мәктәп юк. Гимназия үз мөхите белән авыл мәктәбенә якынрак. Минем шәһәр гимназиясендә эшләп карыйсым килде. Минем хыялым тормышка ашты дип уйлыйм.



- **Сез 30 ел эшләү дәверендә сыйныф җитәкчесе буларак, бик күп укучыларны зур тормыш юлына озаткансыз. Хәзер бишенче сыйныф укучыларын каршы алдыгыз. Алар - нindirәк балалар?**
- Эйе, бик күп укучылар белән эшләргә туры килде. Гимназиядә балаларын да үз итәргә өлгердем инде. Мин алар өчен яңа укытучы булсам, алар минем яңа укучылар бит. Беренчедән, алар сыйныфта күп, 31 укучы. Икенчедән, каникулдан яңа чыктылар. Бик шаяннар, бик хәрәкәтчәннәр, шуклар. Уртак тел табып, бер-беребезне аңлап эшләрбез.
- **Әгәр 1 миллион акча отсагыз, аны нишләтер идегез?**
- Сәяхәт итәр идем.

*Сәхифәне Галиева Камилә әзерләде*

# “Нәниләр сөйли”



Мәктәп еллары - кеше гомеренең кабатланмас матур бер мизгеле. Шуңа күрә баланың мәктәпкә килүе –зур бәйрәм. Ничек шулай булмасын! Бала белем иле юлыннан беренче адымын ясый бит, киләчәгенә юл яра. Алар матур итеп киенгән, күңелләрендә бәйрәм. 1 сентябрь илебезнең бөтен мәктәпләрендә дә һәр бала өчен көтеп алган, кызыклы вакыйгаларга бай булган яңа уку елы башлана. Күңелләрдә сөенеч, йөзләрдә шатлыклы елмаю балкый. Быел безнең гимназия дә 21 бала өчен үз ишеген ачты. Алар мәктәпкә дөрес утырырга, укырга, язарга өйрәнергә килделәр.Бүгеннән алар мавыктыргыч, маҗаралы, ә кайчакта бик кыен да булган сәяхәткә чыгалар. Бу сәяхәт – Белем иленә илтә. Ләкин бу илне карталарга карап табып булмый.Бала Мәктәптә матурлыкка омтыла, якты киләчәгенә кул сузып бара. Алдында биек үрләр, шул үрләрне яулый алса гына ул бәхетле булачак. Аңа шушы үрләрне яулауда, белем алуда укытучы ярдәмгә килә.Белем илен һәркем үзе ача, һәм сезгә бу ачышта ярдәмчегез,сезгә юл күрсәтүчегез, беренче укытучыгыз — Гимадиева Рүзилә Рәуфәт кызы булыр.Сез белем алу теләге белән гимназиягә аяк бастыгыз һәм һәр уку көнегез шулай якты, матур булсын иде дип телибез. Сезгә укуыгызда бары тик уңышлар гына юлдаш булсын!

1. **Мәктәптәге беренче көнегез ничек үтте?**

**Ахметова Самира:** Барысы да матур булды, миңа нык ошады

**Гараева Айгизә:** Матур бәйрәм булды, мин бик шат

**Гиляев Рияз:** Беренче сентябрь-күңелле бәйрәм булды.

**Мадишина Ралина:** Миңа үзебезнең сыйныфның бизәлеше нык ошады. Шундый матур иде.

**Нуриева Азалия:** Күңелле бәйрәм булды! Мин беренче кыңгырауны шалтыраттым. Бәйрәм матур үтте.

2. **Сиңа кайда күбрәк ошый: балалар бакчасындамы, мәктәптәме? Ни өчен?**

**Зотова Рада**: Балалар бакчасында рәхәт иде. Бакча үзебезнең авылда иде бит.

**Салахов Самат:** Миңа гимназиядә бик ошый.

**Яковлева София:** Миңа гимназиядә рәхәт, чөнки мин бик күп яңа дуслар таптым.

**Шаймуратова Мәликә:** Миңа балалар бакчасында күбрәк ошый иде. Әле гимназия белән танышам гына.

**Фәсхиева Риана:** Гимназиядә күбрәк ошый. Көн саен нindидер яңалык көтәм.

3. **Иң яраткан дәресең нинди?**

**Гилмуллина Амелия:** Математиканы яратам.

**Кузнеов Эмин**: Физкультура дәресен бик яратам.

**Миннемуллин Әмир:** Миңа музыка дәресе ошый.

**Махиянов Илназ:** Рус теленә яратып йөрим.

**Борханов Әмир:** Музыка һәм физкультура дәресләрен ошатам.

*Рубриканы Федотова Әдилә әзерләде.*

# Гимназия сулышы



- Гимназиянең 9, 10, 11 нче сыйныф укучылары Татарстан Республикасының атказанган артисты, педагогика фәннәре кандидаты Ильяс Халиковның “Мөнбар” татар театрының “Аклыкка илтсен юллар” концерт-спектаклен карадылар. Программа татар халкының гореф-гадәтләренә таянган, милли традицияләрне үз эченә алган тәрбияви бер тамашаны үз эченә алган. “Аклыкка илтсен юллар” концерт - спектакле хәзерге тормышның проблемаларын, гаилә проблемаларын, әхлаксызлык белән әхлак капма-каршылыгы, үсеп килүче яшь буын һәм өлкәннәр арасындагы конфликт юлларын күрсәтә. Укучылар татар милләтен, татар телен, татар халкының гореф-гадәтләрен саклап калу юллары турында төпле фикерләр белән таныштылар. Тел, гореф-гадәт, милли аң, рухи кыйммәтләр борынгыдан калган байлык-хәзинә – яшь буынны тәрбияләүдә зур роль уйнаганын аңладылар. Спектакль милли эчтәлеккә бай булган җырлар белән үрелеп барды.



- Гимназиянең 8 нче сыйныф укучылары Минзәлә шәһәре шагыйрәләре белән очрашуда булдылар. Шагыйрьләрнең тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштылар, автор - башкаручыларның җырларын тыңладылар. Кичә һәрвакыттагыча тирән эчтәлекле һәм файдалы булды.



- Гимназиядә 8-9 сыйныф укучылары өчен Рәмзил хәзрәт белән очрашу булды. Хәзрәт, тормыштан мисаллар китереп, укучыларга ислам дине кануннары турында сөйләде. Хәдис, аят, сүрә төшенчәләрен кабат исләренә төшерде. Рамазан ае, ураза тоту турында да мәгълүмат бирде. Хәзрәт, үзе белән алып килгән, дин һәм милләт бүләге булган - шамаил белән таныштырды, аның мәгънәсен аңлатты. Хаҗ кылу- ислам дине баганаларының берсе икәнен исбатлады. Хәзрәт үзенең әңгәмәсен «Ике кече хаҗ кылу арасында кеше барлык гөнаһларыннан котыла, ә зур хаҗ өчен бүләк булып оҗмах тора»- дип тәмамлады. Укучылар үзләрен кызыксындырган сорауларга да җавап алдылар.

- Казанда Г.Тукай исемендәге татар дәүләт филормониясендә “ТАТАР СҮЗЕ” V нче Халыкара нәфис сүз телевизион бәйгесенә йомгак ясалды. Бәйге Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе, “Татарстан-Яңа гасыр” телерадиокомпаниясе ярдәме белән уздырылды. Бәйгенең максаты - татар телен, әдәби мирасыбызны пропагандалау, үстерү һәм саклау; татар классик язучыларының әсәрләрен популярлаштыру, татар

әдәбиятына һәм мәдәниятенә кызыксыну уяту. Катнашучыларның эшләре 3 яшь категориясендә бәяләнде. Барлыгы 4500 эш тапшырылган һәм катнашучыларның 38-е җиңүче дип танылган. Гимназиянең 7 нче сыйныф укучысы Иванов Искәндәр, 8-13 яшьлек катнашучылар арасында “Шигърият” номинациясендә Зиннур Насыйбуллинның “Татар теле” әсәрен яттан сөйләп, җиңүче булды. Аңа “ТАТАР СҮЗЕ” бәйгесенең 2 дәрәҗә дипломы һәм 45 меңлек сертификат тапшырылды. Искәндәрне зур җиңүе белән котлыйбыз һәм киләчәктә дә уңышлар телибез!!!




- Быел Әтнә районы Каенсар урманнарында урнашкан “Апуш” студиясе җитәкчелегендә “Күзлек” балалар театр лабораториясе ачылды. Анда 7-17 яшьтәге «Апуш» татар балалар театр студиясе һәм Әлмәт, Чаллы, Минзәлә, Саба, Балтач, Әтнә, Апас, Арча районнарының театр студияләрендә шөгыльләнүче 117 бала катнашты. 15 көн дәвамында, 10 августан 25 августка кадәр, балалар театр сәнгате серләренә төшенделәр. Безнең гимназиянең Рөстәм Муллин исемендәге “Сәяр” балалар театры һәм киностудиясенең 5 укучысына: Адилә Миннемуллина, Азалия Апанаева, Искәндәр Иванов, Самат Батталов һәм Илмир Гаязовка“Апуш” иҗади лагерында ял итү бәхете елмайды. 2 атна дәвамында катнашучылар «Чулпан» балалар лагеренда яшәде. Лаборатория кысаларында алар төрле остаханәләрдә, чакырылган кунаклар белән иҗади кичәләрдә катнаштылар,көнгә 5 тапкыр туклandылар, сәламәтлекләрен ныгыттылар, театр сәнгате серләренә тирәнтен төшенделәр. Аларга танылган артистлар мастер - касслар уздырды, театр дөньясы белән якыннан таныштырды. Бигрәк тә Нурбәк Батулла уздырган “Уй һәм тән иркенлеге” дигән мастер - класста балалар яратып фикер алыштылар. Ял итү дәверендәТуфан Миңнуллин әсәрләренә 4 эскиз әзерләделәр һәм аларны яклап чыктылар. Эскизларда мәхәббәт һәмнәфрәт кебек катлаулы хисләргә кыска һәм оста гына аңлатма бирделәр. 25 август көнне, Г.Камал театрының яна бинасында, Туфан Миңнуллинның тууына 90 ел тулуга багышланган “Күзлек” театраль лабораториясенең йомгаклау кичәсе узды. Төрле районнардан җыелган 4 баланысайлап алып, аларга кичәне алып барырга мөмкинчелек тә бирелде. Алып баручылар арасында безнең гимназия укучысы Адилә Миннемуллина да булды. Балалар, киләсе елга да “Апуш” лагерына бару теләге беләнилһамланып, рухи байлык җыеп кайттылар.



# *Куңелле тәнәфес*





| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| З | Ж | К | О | Г | Е | Ы | Н | О | Ю |
| Р | И | О | Д | Ө | З | Р | А | Б | Л |
| А | К | Р | И | М | Б | О | Р | Ы | С |
| Ф | П | А | Л | О | А | Р | Л | А | Н |
| Г | Л | Н | Д | А | К | Ы | С | Б | Ү |
| Е | П | Т | Ө | Я | У | Б | О | Е | Р |
| Р | А | К | Л | Н | О | Я | Л | А | Н |
| Д | З | Е | А | Ю | Д | Ө | Г | А | И |
| Б | Е | А | Й | Я | Ф | И | К | Т | Е |
| Р | А | М | М | Ы | Л | Л | Е | Р | П |





Рәсемнәрдә сурәтләнгән хайваннарның исемнәрен башваткычтан табыгыз.
Бер сүз билгеләп куелган инде. Артып калган хәрефләрне буш шакмакларга дөрес язсагыз, хайваннар дөньясын өйрәнүче фән исеме килеп чыгар.